ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучыларны бер муниципаль район составына керә торган җирлекләр арасында, шәһәр округы составындагы торак пунктлар арасында түләүсез йөртүне оештыру тиешле мәгариф оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан башкарыла. Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучыларны төрле муниципаль районнар составына керә торган җирлекләр арасында, шәһәр округлары арасында, җирлек һәм шәһәр округы арасында түләүсез йөртүне оештыру, күрсәтелгән муниципаль берәмлекләр территорияләрендә укучыларның яшәү урыны буенча тиешле мәгариф оешмаларына транспорт белән йөрү мөмкинлеге тәэмин ителмәгән очракта, тиешле мәгариф оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан башкарыла.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 3 өлеш өстәргә:
«3. Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмасын гамәлгә куючының әлеге мәгариф оешмасында белем ала торган һәм укучыларның яшәү урыннары буенча тиешле мәгариф оешмаларына транспорт белән йөрү мөмкинлеге тәэмин ителмәгән башка

муниципаль район яки шәһәр округы территориясендә яшәүче укучыларны түләүсез йөртүне оештыруга чыгымнары җирле бюджетлардан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирү өчен Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган тәртиптә күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең бюджет акчалары исәбеннән компенсацияләнергә тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон нигезләмәләре, 2020 елга бюджетлардан башлап (2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына), Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә килеп чыга торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БУЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 09 декабрь
№ 96-ТРЗ